Мордовиядә яшәvче, әтисе сак-лап калу максатыннан биргән миллион ярым сумнан артык акчасын, мошенникларнын «Куркынычсыз счетына» кvчергән!

Россия Эчке эшләр министрлыгынын Рузаевка районы буенча дежур частенә 34 яшьлек жирле кеше морәжәгать иткән. Ул ана карата кылынган мошенниклык турында хәбәр иткән. Зыян кvрvче сvзләренчә, 26 ноябрьдә ана башта янәсе ФСБ хезмәткәре, ә аннары «Росмониторинг» вәкиле шалтыраткан. Әнгәмәдәшләр хәбәр иткәнчә, аферистлар анын «Госуслуги» порталындагы шәхси кабинетына керv момкинлеге алган һәм барлык акчаларын урларга момкиннәр. Санкцияләнмәгән гамәлләрне булдырмау очен акчаларны кулга тошерергә һәм куркынычсыз счетка кvчерергә кирәк, дигәннәр. Шалтыратучыларнын кvрсәтмәләре буенча, гариза бирvче банкка юл тота, анда әтисенен 1 миллион 600 мен сум акчасын алып, аны саклап калу максатыннан тапшыра. Шуннан сон ул телефонга тvләv системасы кушымтасын урнаштыра һәм ботен акчаны банкомат ячейкасына кертә. Берникадәр вакыттан сон, уздырылган финанс операциясенә карамастан, аферистлар кабат гариза бирvче белән элемтәгә керәләр һәм жинаятьчеләрнен анын акчаларын урларга чираттагы омтылышлары турында сойләшvне дәвам иттерәләр. Алдау корбаны булуын анлап, зыян кvрvче полициягә морәжәгать итә. Хәзерге вакытта мошенниклыкка катнашы булган затларны билгеләvгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы шуны искәртә: шикле финанс операцияләре турында хәбәр ителсә, кичекмәстән сvзне озәргә һәм банк картасынын арткы ягында кvрсәтелгән телефон номерына шалтыратырга кирәк.
Сак булыгыз!